СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

29.08.2025 № 61/6

На №_________ от______________

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе турында» Тукай муниципаль районы Советының 2011 елның 27 декабрендәге 9/9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 6 февралендәге 66 номерлы карарын үтәү йөзеннән, район уставы нигезендә, кадрлар үзгәреше сәбәпле, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе турында» Тукай муниципаль районы Советының 2011 елның 27 декабрендәге 9/9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составыннан чыгарырга:

Бакирова Эльза Радик кызын;

Насыйров Айрат Марат улын;

1.2. балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Галиуллина Айсылу Сабит кызын | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазифасында, комиссия рәисе; |
| Җаббарова Алсу Арслангали кызын | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры; |
| Низамиева Азалия Ринат кызын | башлык ярдәмчесе, Тукай муниципаль районының «Беренчеләр Хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте җирле бүлекчәсе рәисе вазифасында. |

2. Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе составын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет рәисе урынбасары Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2025 елның 29 августындагы 61/6 номерлы карарына кушымта

**Тукай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Галиуллина А.С. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары – комиссия рәисе; |
| Низамиева Э.Р. | «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы – комиссия рәисе урынбасары; |
| Рафикова Л.В. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районындагы халыкны социаль яклау бүлеге башлыгы – комиссия рәисе урынбасары; |
| Хөснетдинова Г.Т. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе баш белгече – комиссиянең җаваплы секретаре. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гәрәев И.Р. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Шәябтдинов А.А. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча полиция бүлеге башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча), полиция подполковнигы; |
| Лымарь Р.Р. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы; |
| Хәкимова Э.В. | Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ДКУ Яр Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча департаментының Тукай районы буенча гражданнарны кабул итү бүлеге башлыгы; |
| Сафина Л.Р. | «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгының тәрбия эшләре буенча урынбасары; |

| | |
|---|---|
| Зиятдинова А.Р. | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тукай муниципаль районында «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры вазифаларын башкаручы; |
| Җаббарова А.А. | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры; |
| Халикова А.Ф. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы мөдире; |
| Мифтахов И.И. | Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы; |
| Салихов И.З. | Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе федераль казна учреждениесенең Тукай районы буенча филиалы башлыгы урынбасары; |
| Низамиева А.Р. | башлык ярдәмчесе, Тукай муниципаль районының «Беренчеләр Хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте җирле бүлекчәсе рәисе; |
| Бузина Н.К. | муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы; |
| Латыйпова Г.З. | Тукай муниципаль районының психология-педагогика социаль үзәге җитәкчесе; |